**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 18 декабря 2013 года г. Казань № 6-46/тп

***Татарстан Республикасы җирендә урнашкан челтәр оешмаларының челтәренә 15кВт тан югары булмаган энергияне кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру максаты белән гариза бирүчеләр өчен, технологик тоташтыру хезмәте өчен түләү зурлыгын билгеләү турында (әлеге ноктага аннан алда тоташтырылган энергияне кабул итүче җайланмаларны исәпкә алып)***

Россия Федерациясе законына туры китерү максатыннан чыгып, “Электр энергетикасы турында” 26 март, 2003 ел, № 35-ФЗ Федераль законга, “Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында” 29 декабрь, 2011 ел, № 1178 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 27 декабрь, 2004 ел, № 861, Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Электр энергиясен кулланучылар, электр энергиясе объектлары тарафыннан электр кабул итү җайланмаларын тоташтыруның технологик кагыйдәләре, шулай ук челтәр оешмалары һәм башкалар исәбендә булган электр челтәре хуҗалыклары”, “Электр челтәренә технологик тоташтыру өчен түләү күләмен исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” 11сентябрь, 2012 ел, № 209-э/1 Федераль тарифлар хезмәте боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь, 2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы җирендә урнашкан челтәр оешмаларның челтәренә максималь куәте 15кВт тан (әлеге ноктага аннан алда тоташтырылган энергияне кабул итүче җайланмаларны исәпкә алып) югары булмаган энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру өчен, әгәр дә гариза бирүче биләмәсендә өченче ышанычлылык категориясенә караган объектлар (электр белән тәэмин итүче бер нокта алына) бар икән, әгәр дә гариза бирүченең җир чиге, гариза бирүчегә кирәк булган челтәр оешманың көчәнеш классы, көчәнеше 20 кВтан югары булмаган электр челтәре хуҗалыгының чигеннән шәһәрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метр, авыл җирендә 500 метрдан да зуррак булмаган, түләү зурлыгы 550 сумны тәшкил итә дип билгеләргә.

2. Муниципаль районнар, шәһәр округы һәм федераль мөһимлеге булган шәһәрләрнең шәһәрэче территорияләрендә, бер үк шәхес аңа законлы нигездә

караган, әлеге карарның кушымтасындагы 1нче пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килүче, энергия кабул итү җайланмаларын, 3 ел эчендә 1 тапкырдан да күп булмаган, тоташтыру өчен 550 сум түләп, технологик тоташтыра ала.

3. Әлеге карарның 1нче пунктында күрсәтелгән технологик тоташтыру өчен түләү түбәндәге очракларда алынмый:

3.1. Бер елдан күбрәк булмаган аренда килешүе нигезендә җиргә хуҗа булган шәхесләрнең җирендә урнашкан энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру очрагында;

3.2. Күп фатирлы өйләрнең торак бүлмәләрендә урнашкан энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру очрагында.

4. Бакча, коммерциясез дача берләшмәләре һәм башка коммерциясез берләшмәләргә килгәндә (гараж-төзү, гараж кооперативлары), технологик тоташтыру өчен түләүне 500 сум зурлыгында билгеләргә, бу зурлык оешмаларда булган кеше башына тапкырлана, әгәр дә әлеге берләшмәләрнең һәр члены 3 ышанычлылык категориясе (электр белән тәэмин итүче бер чыганак буенча) 15кВт тан да зуррак булмаган тоташтыру ясый икән, моннан алда челтәр оешманың электр челтәренә 20 кВ ка кадәр зурлыктагы көчәнешле әлеге энергия кабул итү ноктасын тоташтыруны исәпкә алып, әгәр дә алда әйтелгән берләшмәләрнең энергия кабул итүче җайланмалары электр челтәре оешмаларының объектларыннан шәһәрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метр, авыл җирендә 500 метрдан да зуррак булмаган ераклыкта урнашу очрагында.

5. Үз гаражларын һәм хуҗалыкларын (баз, сарай) берләштергән гражданнар өчен технологик тоташтыру өчен түләүне 550 сум зурлыгында билгеләргә, әгәр дә һәр бу каралтыларның хуҗалары челтәр оешмаларның челтәренә максималь куәте 15кВт тан (әлеге ноктага аннан алда тоташтырылган энергияне кабул итүче җайланмаларны исәпкә алып) югары булмаган энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру өчен, әгәр дә гариза бирүче биләмәсендә өченче ышанычлылык категориясенә караган объектлар (электр белән тәэмин итүче бер нокта алына) бар икән, әгәр дә гариза бирүченең җир чиге, гариза бирүчегә кирәк булган челтәр оешманың көчәнеш классы, көчәнеше 20 кВтан югары булмаган электр челтәре хуҗалыгының чигеннән шәһәрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метр, авыл җирендә 500 метрдан да зуррак булмаган очракта.

6. Дини оешмаларның электр энергиясен кабул итүче җайланмаларын технологик тоташтыру өчен түләүне 550 сум зурлыгында билгеләргә, әгәр дә челтәр оешмаларның челтәренә максималь куәте 15кВт тан (әлеге ноктага аннан алда тоташтырылган энергияне кабул итүче җайланмаларны исәпкә алып) югары булмаган энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтырыла икән, әгәр дә гариза бирүче биләмәсендә өченче ышанычлылык категориясенә караган объектлар (электр белән тәэмин итүче бер нокта алына) бар икән, әгәр дә гариза бирүченең җир чиге, гариза бирүчегә кирәк булган челтәр оешманың көчәнеш классы, көчәнеше 20 кВтан югары булмаган электр

челтәре хуҗалыгының чигеннән шәһәрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда 300 метр, авыл җирендә 500 метрдан да зуррак булмаган очракта.

7. Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты идарәсе, 20 ноябрь, 2009 ел, № 6-6/тп карарын "Татарстан Республикасы җирендә урнашкан челтәр оешмаларның челтәренә максималь куәте 15кВт тан (әлеге ноктага аннан алда тоташтырылган энергияне кабул итүче җайланмаларны исәпкә алып) югары булмаган энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру өчен түләү зурлыгын билгеләү һәм Татарстан Республикасы җирендә урнашкан челтәр оешмаларының электр тарату челтәренә куәте 15кВт тан да зуррак булмаган (әлеге ноктага аннан алда тоташтырылган энергияне кабул итүче җайланмаларны исәпкә алып) энергия кабул итүче җайланмаларны технологик тоташтыру өчен гариза бирүчеләрдән түләү алу кагыйдәләрен раслау турында" көчен югалткан дип исәпләргә.

8. Настоящее постановление вступает в силу по истечении десяти дней после дня его официального опубликования.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов